**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№1705**
**07.03.2025**

«Горкоммунхоз» МУП тарафыннан
күрсәтелә торган хезмәтләргә
тарифларны раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 17 статьясы 1 өлешенең 4 пункты, шәһәр Уставының 41 статьясы, Шәһәр Советының 2008 елның 19 ноябрендәге 35/7 номерлы Карары белән расланган Муниципаль предприятиеләрнең һәм учреждениеләрнең хезмәт күрсәтүләренә тарифлар билгеләү турында карарлар кабул итү тәртибе хакында нигезләмәнең 5 пункты, Башкарма комитетның 2013 елның 1 ноябрендәге 6561 номерлы Карары белән расланган муниципаль унитар предприятиеләрнең һәм муниципаль учреждениеләрнең хезмәт күрсәтүләренә тарифларны исәпләү тәртибе турында нигезләмә нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. «Горкоммунхоз» МУП тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифларны кушымтада каралганча расларга.
2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе башлыгы Р.Ф. Вилдановка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе — Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2025 елның 7 мартындагы
1705 номерлы карарына
кушымта

«Горкоммунхоз» МУП тарафыннан күрсәтелә торган
хезмәтләргә тарифлар

| № т/б | Хезмәтнең исеме | Бәясе, сум | Үлчәү берәмлеге |
|---|---|---|---|
| 1. | SOLLERS Atlant автобусы белән оешмаларның пассажирларын йөртү (вахта), ягулык-майлау материалларын исәпкә алып | 2499, 68 | 1 сәгать |
| 2. | НЕФАЗ маркалы автобуслардагы реклама-мәгълүмат конструкциясендә мәгълүмат урнаштыру | 478, 02 | аена 1 хезмәт |
| 3. | Автотранспортны ремонтлау | 1600, 00 | 1 сәгать |
| 4. | НЕФАЗ автобусын Яңа ел бәйрәменә электр гирляндалары белән бизәү | 272 946, 77 | 1 автобус |

Башкарма комитет Аппараты Җитәкчесе
урынбасары, эш кәгазьләрен алып бару
идарәсе башлыгы вазыйфаларын башкаручы Г.А. Шәфыйкова